МОУ «Школа №33»

# Школа радости

№ 19
2011 г.

Газета школы №33 Авиастроительного района города Казани

## *26 апрель* - бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 125 ел



*Язы барның җирдә җыры булыр,*
*Язлар бирде сине бу җиргә.*
*Зур җаннарга гына насыйптыр шул*
*Гасырларга үтеп керергә.*
*Җыры барның җирдә даны булыр,*
*Бәйрәмнәре булыр мәңгегә.*
*Без бәхетле, без шагыйрьле халык,*
*Без - Тукайлы халык мәңгегә!*
*(Э. Шәрифуллинадан)*

## *Тукай безнең күңелләрдә!*

Габдулла Мөхәммәтгариф углы Тукаев 1886 елның 26 апрелендә Кушлавыч авылында мулла гаиләсендә дөньяга килгән. Биш ай чагында аның әтисе, ә 4 яшьлек чакта әнисе дә үлеп китә. Габдулла кече яшьтән ятим калып, кулдан-кулга күчеп йөрү михнәтләрен күргән. Ләкин шул кыенлыкларга карамыйча, Габдулла Тукай татар әдәбиятының тарихында бик зур эз калдырган. Үз гомерендә ул 34 китап яза, аларның уналтысы – балалар өчен.

Тукай тормышын өч чорга бүлеп карап була: Кырлай, Җаек (Уральск), Казан чорлары. Кырлайда Сәгъди абзый йортында үткән берничә ел яшь Габдуллага крестьян тормышының авырлыгын һәм матурлыгын аңлау юлында беренче тәҗрибәне биргән. Сәгъди абзый Тукайны эшкә өйрәтә һәм хезмәт иясенә хөрмәт тәрбияли. Кырлайда Габдулла укырга йөри башлый. Кырлай мәдрәсәсендә булачак шагыйрьнең белем нигезе салына. Кырлайда туган беренчс уй-тойгылары Тукай поэзиясенең күп кенә илһамлы юллары, темалары булып китүе дә мәгълүм. “Шүрәле” әкияте үзе генә дә Кырлай истәлегенең гүзәл бер шигъри һәйкәле булып санала. “Пар ат” һәм “Туган җиремә” кебек шигырьләре дә Кырлай истәлекләре белән рухланган.

1895 елда Габдулла Тукай Җаекка атасының сеңлесе Газизә Зәбирова тәрбиясенә алына. Шунда ул мәдрәсәгә укырга керә. “Мотыйгыя” мәдрәсәсендә башкалардагы кебек вак-төяк кысынкылыклар булмаган. Анда шәкертләргә өлешчә ирек бирелгән. Шуның өстенә, XX йөз ахырларында Рәсәйдә мәгърифәтчелек һәм яңача укыту хәрәкәтләре көчәя. Булачак шагыйрь өчен шушы шартлар иҗаты ачылуга ярдәм итә.

1907 елның көзендә Габдулла Тукай туган якларна кайта һәм Казанга килеп урнаша. “Әл-ислах” исемле журналда һәм “Китап” нәшриятында җиң сызганып эшләүчеләрнең берсе булып китә. Казанга килгәннән бирле беркая чыкмый яшәгән шагыйрь, сәламәтлегенең гаять начарлануына карамастан, 1911-1912 елларда берничә тапкыр сәяхәткә бара. 1913 елның 2 апрелендә Габдулла Тукай Казан шәһәрендә вафат була. Безнең өчен ул мәңгегә иң бөек шагыйрь булып кала!

**Булат КАМБЕЕВ, 9 Б**

# *Без - Тукайлы халык!*

Шагыйрьнең туган ягы – инешле, чокырлы, урманлы Казан арты. Монда әүвәл-әүвәлдән җирне урманнан яулап алганнар, җир азлыктан иза чиккән. Монда зур сулар, зур болыннар да юк, биек таулар, коялар да юк. Казан артының исә төп матурлыгы Шүрәлеле калын урманнарында; кырыенда тал куаклары сыгылып утырган, Су анасы яши торган суларында!

Шул төбәкнең Кушлавыч авылында 1886 елның 26 (14) апрелендә мулла Мөхәммәтгариф гаиләсендә Габдулла Тукай дөньяга килә. Малай туып дүрт ай ярым үткәч, Мөхәммәтгариф хәзрәт үлеп китә. Тол калган Мәмдүдәне (Габдулланың әнисен) Сасна муласына кияүгә бирәләр. Бәләкәй Габдулланы авылның Шәрифә исемле фәкыйрь бер карчыгына вакытлыча асрамага калдыралар. Әнә шуннан шагыйрьнең газаплы, авыр тормышы башлана. Габдулла монда ятимлекне генә түгел, ачлыкны да татый. Бабасы, күрше авыллардан икмәк сыныклары теләнеп алып кайтып, балаларын ач үлемнән саклый. Ә бервакыт баланы, Казанга баручы бер ямщиккә утыртып, ерак, билггесез сәфәргә озаталар. Теге ямщик исә Печән базарына килгәч: «Асрарга бала бирәм, кем ала?» - дип кычкырып йөри.

Халык арасыннан бер кеше чыгып малайны үзләренә алып кайта. Яңа бистә һөнәрчесе Мөхәммәтвәли абзый белән Газизә абыстай шулай итеп малайлы булалар. Соңрак аны яңадан Өчилегә озаталар. Бераздан соң малайны Кырлай исемле авылдан баласыз Сәгъди абзыйга уллыкка озаталар.

Шулай рухи яктан авыл, крестьян тормышын тәмам күңеленә сеңдергән Тукайны көннәрдән бер көнне Кушлавыч авылының Бәдретдин исемле кешесе эзләп таба да, аны Уральскига алып китә...

**Илнар ЯҺУДИН**



# *Бөек шагыйрь*

Габдулла Тукай исеме Татарстанда гына түгел, чит илләрдә дә таныш. Аны сәнгатьне, поэзияне яраткан һәрбер кеше белә. Тукайның иҗаты күпкырлы: ул шагыйрь, публицист, әдәби тәнкыйтьче дә. Татар әдәбиятын үстерүдә ул бик зур өлеш кертә.

Уральск шәһәрендә аның балачагы һәм яшьлеге үтә. Монда ул мәдрәсәгә укырга керә һәм шигырьләр яза башлый. Бу шәһәрдә яшь Тукай А.С. Пушкин, М.Ю. Лермонтов иҗаты белән таныша. Аларның шигырьләре Тукай йөрәгенә үтеп керә. Уральскида Тукай типографиягә эшкә урнаша, ләкин озак эшли алмый, аны эштән куалар һәм аның алдында: «Кая барырга?» - дигән сорау туа. Ул Казанны сайлый. Казанда Г. Тукай Фәтих Амирхан, Галиәскар Камал һәм башка бик күп атаклы язучылар белән таныша, үзе дә күп әсәрләр иҗат итә. Шулар арасында «Туган тел», «Шүрәле» һ.б.

Тукайның сәламәтлеге начарлана, аны шифаханәгә салалар. 1913 елның 11 апрелендә Тукай вафат була, ләкин халык аның иҗатын мәңге онытмый.

**Руслан КАБИРОВ, 4 А**

# Сөйкемле Шүрәле

Габдулла Тукай – минем иң яраткан язучым. Миңа ике-өч яшь булганда дәү әни миңа һәр көн Тукай әкиятләрен һәм шигырьләрен сөйли иде. Хәзер дә мин Тукай китапларын алып укырга яратам. Минем иң яраткан әкиятем – «Шүрәле». Бу әкиятне дәү әнием миңа күп тапкырлар сөйләгән иде, ләкин мин аны укыгач башкача аңлый башладым. Әкиятне тыңлаганда мин: «Бу Шүрәле менә нинди начар икән – ул кешеләрне кытыклап үтерә! Ә бу егет бик батыр, яхшы һәм хәйләкәр кеше икән, ул Шүрәлене бик оста алдады», - дип уйлый идем. Хәзер шуның белән беррәттән миндә яңа фикерләр дә туды.

Габдулла Тукай табигатьне бик яраткан. Аның турында бик күп искиткеч шигырьләр, хикәяләр язган ул. Һәрбер әсәрдә табигатьнең матурлыгын күрсәткән. Күп кенә әсәре белән ул кешеләргә: «Табигатьне саклагыз!» - дип әйтә кебек. «Шүрәле» әкиятендә дә нәкъ шулай. Егет урманга утынга бара. Һәр кеше шулай урманга барып утын киссә, урманнан нәрсә кала соң? Ә Шүрәле, бәлки, табигатьнең сөйкемле сакчысы буларак күрсәтеләдер? Әкияттә ул егеткә булышырга да ризалаша, ә егет аны алдалап бармагын кыстырып урманда ташлый.

Бүгенге көндә кешеләр табигатьне сакламыйлар. Елгалар пычратыла, хайваннар үлә, күп кенә үләннәр, агачлар юкка чыга. Габдулла Тукай табигатьне сакларга тырышкан. Безне дә шуңа чакыра!

**Ләйсән МИФТАХОВА, 6 Б**

# Кто такой Шурале?

Оказывается, корни этого образа уходят в глубокую древность, окутаны таинственными легендами и мистическими поверьями... Но чем дальше наши предки уходили от язычества, тем меньше оставалось в окружающем мире мистики. Постепенно ужасающий лесной дух превратился в незлое, почти безобидное существо.

Термин «Шурале» в различных вариантах распространён среди народов Урало-Поволжья: татар, башкир, чувашей. Прообраз Шурале бытовал не только в татарской мифологии. У разных народов Сибири и Восточной Европы (а также у китайцев, корейцев, персов, арабов и других).




Известный ученый этнограф, путешественник *Владимир Николаевич Басилов* дает более полное описание образу Шурале: «Термин «Шурале», видимо, восходит к древнему названию божества, близкого образу духа почитаемого предка щур (чур) в славянской мифологии. У татар представляется в образе волосатого мужчины с рогом на лбу или голой женщины с длинными руками с длинными пальцами, нередко – только тремя); у башкир – часто также человекоподобным существом с одним глазом во лбу, на одной ноге, иногда – бревном. Шурале занимается охотой, любит ездить на лошадях, имеет жён и детей. В одном лесу могут жить несколько Шурале. Он сбивает людей с пути, заманивает в чащу, может защекотать до смерти. Боится воды: считалось, чтобы спастись от него, надо перескочить через ручей. Шурале можно поймать, уговорив засунуть палец в расщеплённое дерево, а затем выдернув клин».

**Подготовила Аида ГИЛЬМАНОВА, 5 Б**

# Викторина сораулары

## Габдулла Тукай иҗатын беләсезме?

1. Г. Тукайның 1908 нче елда язган, мәдрәсә тормышын сурәтләгән, анда укыган татар шәкертләренең зирәклеген, тапкырлыгын күрсәтүче шигырен атагыз.
2. «И мөкаддәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?» дигән юллар кайсы шигыреннән алынган?
3. Г. Тукайның Кисекбашы ничә тапкыр хаҗга барган?
4. Кәҗә белән Сарыкның капчыгында ничә бүре башы була?
5. Г. Тукай язышып, аралашып торган газеталарның исемнәрен атагыз...
6. «Шүрәле» балетын язган композитор?
7. Г. Тукай яшәгән кунакханәләрне атагыз...
8. Г. Тукай «Ике кояш» шигырен кемгә багышлап язган?
9. Г. Тукай «Әллүки» җырын кемнән ишетә?
10. Бер шигырендә Тукай кайсы яшелчәне «җәдит» дип данлый?
11. Казанда Г. Тукайның әдәби музееның кем җитәкли?
12. Г. Тукай иҗатын өйрәнүче галимнәрне атагыз. Нинди хезмәтләрен беләсез?
13. Тукайның замандашларын атагыз. Г. Тукайга мөнәсәбәтләре ?
14. Тукайга багышланган әдәби әсәрләрне атагыз.
15. Тукай исемен мәңгеләштерүгәниләр эшләнгән. эшләнәсе эшләргә тәкъдимнәрегез?

**Мәңгелек кеше**

*Тукай бөек шагыйрь булган,*
*Ләкин бик аз яшәгән.*
*Кыска гына гомерендә*
*Яшен кебек яшьнәгән!*

*Күп әкиятләр язган ул,*
*Чыгарган күп шигырьләр,*
*Аның шигырьләрен һаман*
*Сөйли бөек шагыйрьләр.*

*Ятимлектә үскән Тукай,*
*Бер мескен булып туып.*
*Халык күңелендә яши*
*Мәңгелек кеше булып!*

***Алисә ШӘЙХИЕВА, 6 В***







**Редактор:** Ляйсан Фанисовна Тукмачева
**Редколлегия:** Илюза Хамидуллина, Яна Сиразиева, Лилия Заббарова, Алиса Шайхиева, Зарина Мубаракова

**Верстка:** Ляйсан Фанисовна Тукмачева

**Наш адрес**: 420037, Казань, ул. Симонова, д. 17, каб. 18
ПРЕСС-ЦЕНТР
**Телефон:** (843) 510-78-10

**E-mail:** kazan-school33@yandex.ru

**Сайт школы:** www.kazan33.ru